# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

**29.11.2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктында автомобиль юлының киңлеген арттыру (юл кырыйларын вакланган вак таш белән салу һәм ныгыту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү));

2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пунктындагы чишмә территориясен төзекләндерү, чишмәгә юлны ремонтлау);

3) ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш торак пункты зираты территориясен төзекләндерү (дренаж канавын (чокырларын) тәртипкә китерү, төбен тигезләү һәм ныгыту);

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Яңа Минзәләбаш авылындагы мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннәнсоң 10 көн эчендә урнаштырып халыкка чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы Башлыгы Р. Ә. Кәримов